КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 28 гыйнвар г.Казань № 41

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын бирү тәртибе турында» 2007 ел, 20 сентябрь, 475 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фондының торак урыннарын бирү тәртибе турында» 2007 ел, 20 сентябрь, 475 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 15 ноябрь, 936 нчы; 2013 ел, 10 июнь, 395 нче; 2013 ел, 2 ноябрь, 836 нчы; 2016 ел, 19 апрель, 239 нчы; 2017 ел, 28 июнь, 447 нче, 2019 ел, 30 апрель, 372 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы махсуслаштырылган торак фондыннан торак урыннары бирү тәртибенең 2.2 пунктының «е» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«е) хезмәт кенәгәсенең күчермәсе яки хезмәт эшчәнлеге турында кәгазьдә расланган белешмә яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән (эш бирүченең булганда) имзаланган электрон документ рәвешендә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин